# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Мәлки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2020 елның 16 ноябре** **№ 1**

« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004елның 28 июлендә 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 11 ноябрендә 11 сәгать 30 минутта, 2020 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2020 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Мәлки авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

-Мәлки авылында санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;

- Мәлки авылындагы урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;
- Мәлки авылында су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;
- Мәлки авылында су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының капитажын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документлар белән рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар ясау);
- Мәлки авылында материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- Мәлки авылында җәйге чорда үлән чабу;
- Мәлки авылы зиратларын ремонтлау һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу".

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 368 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 192, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 192 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Мәлки торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

-Мәлки авылында санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;

- Мәлки авылында урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;
- Мәлки авылында су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;
- Мәлки авылында су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының капитажын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документлар белән рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар ясау);
- Мәлки авылында материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- Мәлки авылында җәйге чорда үлән чабу;
- Мәлки авылы зиратларын ремонтлау һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу.» - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков